# *Әнисә Кәримова.*



***(1936 – 2002)*** Кәримова (Галиева) Әнисә Мөхәммәткасыйм кызы Әгерҗе (элекке Красный Бор) районы Салагыш авылында туа. Әтисе Красный Бор район финанс бүлегендә, әнисе балалар бакчасында тәрбияче булып эшли. Озакламый әтисен Актаныш районы Пучы авылына район финанс бүлегенә (ул вакытта Пучы район үзәге) дәүләт доходлары инспекторы итеп күчерәләр. Әнисә ханымның балачагы шушы җырларда җырланган матур табигатьле якларда үтә. Әти-әнисе - Тукайны яттан белүче шигърияткә гашыйк кешеләр. Шигърияткә мәхәббәт кызларына да күчкәндер.

Мөхәммәткасыйм абый фронтка киткәч, гаиләсе Салагыш авылына кайта. Ул чор балалары күргән авырлыкларның һәммәсен кичерергә туры килә.
(Читтән күчеп кайтып кеше өстендә яшәү, өй салу өчен мүк чыгару, кирпеч сугу һ.б.)

(Сизми калдым сабыйлыктан яшьлегемә күчкән чакны. Әткәм гомере белән бергә сугыш алды балачакны.
Әмма яшьлек алып килде тәүге хисләр саф йөрәккә. Сыйпап ятимлек ярасын, булыр кебек гомерлеккә...)

Салагыш, Казан, Иж –Бубый мәктәпләре, Алабуга дәүләт педагогия институты... – инде хәзер мөгаллимә булган ханымны белем үренә алып менгән баскычлар.

Татар һәм рус телләре, әдәбиятлары белгечлеге алган яшь кызны Мамадыш районы Урта Кирмән авылына эшкә җибәрәләр.

Ул чордагы шәкертләреннән шактые укытучылар, газета хәбәрчеләре булып китә. Ә Мәскәү шагыйрәсе, балалар язучысы Нәзифә Кәримова, журналист Шаһинур Әхмәтсафа (Мостафин) – билгеле шәхесләр. Алар укытучылары – шигърият дөньясына юнәлеш биргән остазлары белән рәхмәт хисләрен белдереп аралашып , очрашып яшиләр. (“Сез беренче илһам, чаткысы, гомер буе бара яктысы” – ди аның хакында М.Шаһинур).

Әгерҗе районына күчеп килгәч, Әнисә ханымны Сарсак – Омга урта мәктәбенә немец теле укытучысы итеп билгелиләр.

Үзенә таләпчән мөгаллимә белемен күтәрү өчен Мәскәүдәге 3 еллык чит телләр өйрәнү курсларына немец теле бүлегендә читтән торып укый.

Аннан соң шул ук мәктәптә дистәгә якын ел руслашкан татар балаларына туган телебезне өйрәтә. Шигърият аша телебез матурлыгын күрергә юнәлтеп, шигырь язу серләрен ачып, түгәрәкләрдә укучыларның хисләре уята.

Соңгы елларда Тирсә мәктәбендә татар теле һәм әдәбияты укыта.

Әнисә ханым үзе Салагыш җидееллык мәктәбендә укыганда ук фәне буенча ныклы төпле белем биргән немец теле укытучысы, класс җитәкчесе,

шагыйрь Ганиев Әхкиям абыйлары оештырган шигърият түгәрәгенә йөри. Ул чордагы шигырьләре Красный Бор район газетасында басыла.

“Әгерҗе хәбәрләре”, Удмуртия башкаласы Ижауда чыгучы “Яңарышта”, Алабуга шәһәрендә басыла торган “Алнур” газетасында да мәкаләләре һәм шигырьләре дөнья күрә.

Әгерҗе шәһәр статусы алуга – 50, Әгерҗегә нигез салынуга 350 ел тулу уңаеннан нәшер ителгән “Юбилееӊ белән, Әгерҗем!” һәм “Үз моңым бар җирдә” исемле җыентыкларга да исеме кергән.

## *Аниса Каримова*
## *(1936-2002)*

Аниса Касимовна Каримова родилась в деревне Салауш Агрызского района. Детство проходит в селе Поисево Актанышского района.

После окончания Елабужского педагогического института она направляется учительницей в Мамадышский район в село Среднее Кирманово. После возвращения в Агрызский район преподает в деревне Сарсак-Омга. Стихи ее печатаются в газетах

выпускаемых в Удмуртии и Татарстане. Стихи читаются легко, в них отражаются любовь к природе, дружба.

Аниса Каримова сумела привить любовь к литературе своим ученикам. Среди них детская писательница Н.Каримова, журналист Ш.Мостафин.

**Библиография:**

Күңел чишмәләре: Татарстан Республикасының Әгерҗе төбәгендә яшәп иҗат итүче шагыйрьләрнең шигырьләр җыентыгы, Ижау: Ижевская респ. Типография, 1998. – 318 б.

Кәримова Ә. М. Яшьлегем сиреньнәре: шигырьләр. – Казан: Дело, 1998. – 34 б.

**Аның турында:**

Абзалиева Д. Якты эзе калды, // Яңарыш. – 2002. – 26 июль. – 8 б.